**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 15 июне** **№ 130**

**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Варварино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясына нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Кирельский авылы, Гагарин ур., 1 йорт (административ бина);
- Кирельский авылы, Гагарин ур., 14 ("Раифа" кибете»)
- Кирельский авылы, Түбән ур., 6 йорт (китапханә);
- Ишем авылы, Үзәк ур., 10 (авыл клубы),
- Мордва Каратае авылы, Үзәк урамы, 7 нче йорт (КФҮ бинасы).

3. Әлеге карарны “Идел таңнары” газетасында кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Кирельский**
**авыл җирлеге башлыгы,**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы**
**Кирельский авыл җирлеге Советы рәисе** **Ф.Я. Зиннәтуллин**